**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Совет Сунчелеевского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы**

**423052, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Сунчелеево, ул. Ленина, 76.**
Тел. (8-84344-4-98-24) ОГРН 1021605359632, ОКПО 27839587, ИНН/КПП 1603000740/160301001

---

# КАРАР

№ 28 2021ел, 25 июнь

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 07.02.2019 ел, №81 карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 07.02.2019 ел, №81 карарына үзгәрешләр кертергә.
2. 34 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру»;
20 бүлекнең 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән, хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар»;

20 бүлекнең 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) Индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

16 бүлекнең 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан идарәдә катнашудан тыш, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу), яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер, катнашучысы) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

15 бүлегендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) чит ил гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге Советы Рәисе И.В.Крайнова